| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2024 с.Старое Дрожжаное № 49

«Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Карарын гамәлгә ашыру турында

«Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Карарын гамәлгә ашыру максатларында Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 09 сентябрендәге 679 номерлы (02.10.2013 № 736, 31.01.2014 № 59, 12.02.2014 № 88, 12.05.2016 № 266, 10.02.2017 № 78, 24.08.2017 № 463, 19.10.2017 № 591, 22.08.2019 № 364, 21.01.2021 № 15, 06.04.2023 № 161) карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә **2 бүлекнең 2.8 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2.8. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат социаль өлкәдә Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада (алга таба - ЕЦП) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштырыла.».

2. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 августындагы 466 номерлы (09.04.2018 № 165, 21.01.2021 № 15) «Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» карарына, **2 нче пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада (алга таба - ЕЦП) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштырыла.».

3. «2022 - 2026 елларга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 09 ноябрендәге 605 номерлы карары белән расланган «2022 - 2026 елларга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына, **2 бүлекнең 11 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«- Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматларга ярашлы рәвештә, социаль өлкәдә Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада (алга таба - ЕЦП) дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүматны урнаштыруны тәэмин итү.».

4. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының туклануын оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 01 февралендәге 62 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2 нче пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат социаль өлкәдә Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада (алга таба - ЕЦП) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштырыла.»;

**3 нче пунктны** үз көчен югалткан дип тану.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов